**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сарлы авылы №112-56 09 октябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 70-35 номерлы «Жир салымы турында» карарына (2015 елнын 18 августындагы 147-85 номерлы, 2017 елның 2 августындагы 56-30 номерлы карарлары басмасында) үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының 52 маддәсенең беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 3 августындагы 334-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп,

Сарлы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 70-35 номерлы «Жир салымы турында» карарына (2015 елнын 18 августындагы 147-85 номерлы, 2017 елның 2 августындагы 56-30 номерлы карарлары басмасында), 4 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 6 подпункт белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:
"6) балачактан инвалидлар, инвалид балалар.».

2. Әлеге карар рәсми басма - «Маяк» газетасында басылып чыккан көннән бер ай узгач, үз көченә керә һәм 2015 елның 1 гыйнварыннан физик затларның жир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла, Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә: http://aznakayevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Утырыш рәисе Шәрипов М.Р.